# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Алга торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**28.03.2024 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Саклаубаш авыл җирлеге Алга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Алга торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Алга торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 18 мартындагы 2 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Алга авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Алга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 1 нче номерлы, «Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Алга торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 7 ноябрендәге 2 нче номерлы гражданнар җыены карарларына чараларны түбәндәгечә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

1) Алга торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау.
2) төзелеш материаллары сатып алу һәм су башнясын ремонтлау һәм койма тоту.
3) Торак пункт территориясен төзекләндерү өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
4) Халыкара хатын-кызлар көне, Җиңү көне, сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Алга торак пунктында төрле чаралар үткәрү өчен бүләкләр, алу;

3. Әлеге карарны Саклаубаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина